Артём Здунов: «Хөрмәтле Мордовия халкы. Янадан житди темага - телефон мошенниклыгына кагыласым килә.
Жинаятьчеләр безнен гражданнарны житди жинаятьләр кылырга кvндерә - жәмәгать урыннарында ут тортергә мәжбvр итә. Болар барысы да бvләк алу яки урланган акчаларны кире кайтару сылтавы белән эшләнелә.       Беркемгә дә сер тvгел, бу провокацияләр - безнен дошманнар эше. Еш кына «кармакка» яшьләр һәм пенсионерлар эләгә. Барысына да морәжәгать итәм - уяу булыгыз, билгесез кешеләр белән әнгәмәгә кермәгез. Уйланылмаган гамәлләр реаль тормә срогына китерергә момкин. Моны балаларыгызга, әти-әниләрегезгә, әби-бабаларыгызга анлатыгыз. Эчке эшләр министрлыгынын Мордовия буенча дежур часте - 47-77-71, Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенен РМ буенча дежур хезмәте телефоны - 28-28-28.
Үзегезне һәм якыннарыгызны саклагыз.

***Белэсезме?***

Узган ел Мордовия халкы мошенникларга 450 миллион сумнан артык акча кvчергән. 2024 елнын декабрендә генә Мордовиянен Эчке эшләр органнарына кылынган мошенниклык һәм банк счетыннан акча урлау турындагы гаризалар белән 120дән артык жирле халык морәжәгать иткән. Зыян кvрvчеләргә китерелгән зыяннын гомуми суммасы 34 миллион сумнан артык тәшкил иткән.
Жинаятьләр кылунын ин кин таралган ысуллары булып сим-карта һәм элемтә хезмәтләре договорларны озайту, шулай ук акчаларны резерв счетына кvчереп, билгесез затлар тарафыннан санкцияләнмәгән исәптән чыгарудан һәм кредит рәсмиләштерvдән тора. Шул рәвешле 50 дән артык кеше 22,5 миллионнан мәхрvм калган. Тагын 36 кеше мошенникларга эшкә урнашу һәм акчаларны инвестицияләv сылтавы белән 9,3 миллионнан артык акча кvчергән. Тvләvсез белдерvләр сайтында, социаль челтәрләрдә, популяр маркетплейслар платформасында товарлар сату һәм сатып алу вакытында 15 зыян кvрvче 1,7 миллион сум диярлек югалткан. Барлыгы 2024 елда жинаятьчеләрнен корбаннары 1 мен 400 жирле халык булган, алар 450 миллион сумнан артык мәхрvм калды.